**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУТАЙ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

17 октябрь, 2019 ел №144

**"Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Тутай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Тутай авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 103 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасында "(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);" сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тутай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Тутай авыл**
**авыл җирлеге башлыгы –**
**Тутай авыл җирлеге**
**Советы рәисе Н. М. Насретдинова**